РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Чубар-Абдулловского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д. 81, Азнакаевский район,
с.Агерзе, 423303,
тел./факс (885592)44-5-21
E-mail: Chabd.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Чубар-Абдул авыл җирлеге
башлыгы

Совет ур., 81 йорт, Азнакай районы, Чубар-Абдул авылы, 423323
тел./факс (885592)38-7-37
E-mail: Chabd.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**08 ноябрь 2022 ел** **№7**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатларында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджет проекты турында фикер алышуда катнашу өчен ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10. 2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының 19.04.2012 ел № 50 (27.01.2015 ел №134, 09.09.2015 ел №155, 04.03.2016 ел №30, 10.04.2018 ел №95 карарлар редакциясендә) карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Халык алдында тыңлаулар үткәрүнең инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башлыгы тора.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты-2022 елның 29 ноябере 10.00 сәгатьтә;

- үткәрү урыны- Чубар-Абдул авыл мәдәният йорты;

- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес: Чубар-Абдул авылы, Совет урам, 81йорт.

4. Гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең норматив хокукый актлары һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына бюджеты турында»гы карар проектын Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru. 2022 елның 9 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык Н.Ә. Фәтхетдинов